| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» 02 2025 ел № 95

Балтач муниципаль районы һәм аның составына кергән авыл җирлекләре территориясендә яшәүче гражданнар өчен торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында

Татарстан Республикасының 2015 елның 16 мартындагы «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 13-ТРЗ номерлы Законын, Татарстан Республикасының 2007 елның 13 июлендәге «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында»гы 31-ТРЗ номерлы Законын үтәү йөзеннән, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыкның эксперт-консультация советының 2025 елның 1 февралендәге 40 номерлы хаты һәм торак комиссиясенең 2025 елның 21 февралендәге 3 номерлы карары нигезендә, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзаларының яисә ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү өчен торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен 31769 сум күләмендә кулланырга.

2. Балтач район башкарма комитетының 2024 елның 11 мартындагы «Торак урынның бер квадрат метрының уртача исәп-хисап базар бәясен куллану турында»гы 104 номерлы карарын гамәлдән чыккан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов